ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**12 августа 2016 г.**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 2150**

Зеленодольск районы, Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Солнечная ур., 39 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген алу турында

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 26.09.2013 ел, №2178 карары белән расланган «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында», 2013-2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатларында һәм аларның статусы турында "Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 21.07.2007 ел, №185-ФЗ Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодекслары белән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Зеленодольск районы, Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Солнечная урамы, 39 йорт адресы буенча җир кишәрлеген, шулай ук күрсәтелгән йортта урнашкан күчемсез милек объектларын (кушымтада) алырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм «Зеленодольская правда" газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:
   • чыгарыла торган күчемсез милекнең хокук ияләренә;
   • күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;
   • МКУ "Торак сәясәте департаменты»на җибәрергә.
4. МУ «Зеленодольск муниципаль районы җир мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның 12 августы, №2150
карарына кушымта

Зеленодольск муниципаль районы, Васильево шәһәр тибындагы поселогында, Солнечная урамы, 39 нчы номерлы күпфатирлы торак йортта , урнашкан, авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле күчемсез милек объектлары (торак, торак булмаган биналар) исемлеге

| № кв. |
|---|
| 4 |